**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О единовременной денежной выплате членам семей военнослужащих и лиц, проходивших службу в войсках национальной гвардии Российской Федерации, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины**

В целях материальной поддержки членов семей военнослужащих и лиц, проходивших службу в войсках национальной гвардии Российской Федерации, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины с 24 февраля 2022 года, **постановляю:**

1. Установить единовременную денежную выплату членам семей военнослужащих и лиц, проходивших службу в войсках национальной гвардии Российской Федерации и имевших специальное звание полиции (далее – военнослужащие), погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины с 24 февраля 2022 года, в размере 2 млн рублей в равных долях каждому лицу, определенному в пункте 2 настоящего Указа (далее – единовременная денежная выплата).

2. Установить, что единовременная денежная выплата производится:

супруге (супругу), состоявшей (состоявшему) на день гибели (смерти) военнослужащего в зарегистрированном браке с ним;

родителям (усыновителям) военнослужащего;

лицам, осуществлявшим в отношении военнослужащего обязанности опекуна (попечителя) до достижения им совершеннолетия на протяжении не менее пяти лет;

детям военнослужащего.

3. В целях настоящего Указа к погибшим (умершим) военнослужащим относятся граждане, имевшие место рождения или жительства на территории Республики Татарстан либо захороненные на территории Республики Татарстан.

4. Кабинету Министров Республики Татарстан:

утвердить порядок осуществления единовременной денежной выплаты;

обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с исполнением настоящего Указа, а также принять иные решения по его реализации.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
04 апреля 2022 года
№ УП-233

| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында**

2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. 2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән һәм махсус полиция званиесе булган затларның (алга таба – хәрби хезмәткәрләр) гаилә әгъзаларына 2 млн сум күләмендә, әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән һәр затка бертигез өлештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) билгеләргә.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түбәндәгеләргә бирелә дип билгеләргә:

хәрби хезмәткәрнең һәлак булган (вафат булган) көненә аның белән теркәлгән никахта торган хатынына (иренә);

хәрби хезмәткәрнең әти-әнисенә (аны уллыкка яки кызлыкка алучыларга);

хәрби хезмәткәргә карата ул балигълык чорына җиткәнче кимендә биш ел дәвамында опекунлык (попечительлек) вазыйфаларын үтәгән затларга;

хәрби хезмәткәрнең балаларына.

3. Әлеге Указны үтәү максатларын күздә тотып, һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләргә туган яисә яшәгән урыны Татарстан

Республикасы территориясендә булган яки Татарстан Республикасы территориясендә җирләнгән гражданнар кертелә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне башкару тәртибен расларга;

әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 04 апрель
№ ПУ-233